Олы Кульга авыл җирлеге башкарма комитеты
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы

**КАРАР № 27**

Олы Кульга ав. 3 нче октябрь 2016 ел

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты, «җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясындагы 1 пунктының «в», Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы « Олы Кульга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Олы Кульга авыл җирлеге Советы белән берлектә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Кульга авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итәргә:
«2016 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Олы Кульга авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 200 сум күләмендә үзара салым кертүгә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме:
- Олы Кульга, Олы Осиново, Дон Урай авылларындагы зиратларны төзекләндерү 77000 сум.

ЮК ӘЙЕ".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Олы Кульга авылы, Школьная урамы , 11 нче йорт, Кече Кульга авылы, 1 нче йорт, Дон Урай авылы, Садовый урамы, 2 нче йорт, Олы Осиново авылы, Кооператив урамы , 1 нче йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында (http:// интернет-телекоммуникация челтәрендә (http: / / ribnaya-sloboda.tatarstan.ru к
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районының
Олы Кульга авыл җирлеге башлыгы А.В.Салмин